КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 декабрь г.Казань № 1720

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының фәнни-технологик үсеше» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2022 ел, 27 декабрь, 1429 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының фәнни-технологик үсеше» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2022 ел, 27 декабрь, 1429 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген эшләү, гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт программалары белән идарә итү системасы турында» 2023 ел, 30 май, 655 нче» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «(алга таба – Программа)» сүзләрен «(алга таба – дәүләт программасы)» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгын дәүләт программасының җаваплы башкаручы итеп билгеләргә.»;

3 пунктта «Программа» сүзен «дәүләт программасы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасының фәнни-технологик үсеше» Татарстан Республикасы дәүләт программасын яңа редакциядә (механизм карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин